**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28»февраль 2019 ел № 59

Әтнә муниципаль районы
мәйданы өстендә авиация эшләрен,
парашют сикерүләрен, һава судноларының
демонстрация очуларын, пилотсыз аппаратлар
очуларын, аэростатлар күтәрелүен,
Әтнә муниципаль районы чикләрендә урнашкан
мәйданчыкларга утырту (күтәрелү) өчен рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
аэронавигацион мәгълүмат документларында
басылып чыкмаган административ
регламентын раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Әтнә муниципаль районы уставы нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максаты белән

карар бирәм:

1. Әтнә муниципаль районы мәйданы өстендә авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының демонстрация очуларын, пилотсыз аппаратлар очуларын, аэростатлар күтәрелүен, Әтнә муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга утырту (күтәрелү) өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең аэронавигацион мәгълүмат документларында басылып чыкмаган административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе: А.Ф.Каюмов